# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Янурыс авыл җирлегенең Янурыс авылы торак пунктында
2021 елда үзара салым кертү турында

**2002 елның 11 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлегенең Янурыс авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге Янурыс авылы торак пунктында I төркем инвалидларыннан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 250 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Янурыс, Иске Әхмәт авылларында урам, йорт номерлары, элмә такталары (килешү буенча түләү) сатып алу;

2) Балалар уен мәйданчыгын сатып алу һәм аны Янурыс торак пунктында Ленин урамы 43А адресы буенча урнаштыру(килешү буенча эшләр өчен түләү);

3) Спорт мәйданчыгы сатып алу һәм аны Янурыс торак пунктында Ленин урамы 43А адресы буенча урнаштыру(килешү буенча эшләр өчен түләү);

4) Яңа елны бәйрәм итү өчен костюмнар сатып алу;

5) Янурыс, Иске Әхмәт авылларында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (светодиод лампалар сатып алу һәм урнаштыру);

6) МТЗ-82.1 тракторын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү );

7) Янурыс авылында бәйрәмнәр һәм чаралар үткәрү өчен бүләкләр алу;

8) Янурыс торак пунктында Яр буе, Комсомольская урамы буенча югары агачларны кисү.

3. Әлеге карарны Янурыс авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Янурыс авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче А. Ә.Мөхәммәдиева